ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи, 422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КУРАЛОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы, 422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

26.09.2023　　　　　с. Куралово　　　　　02-02/2

Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Рус Бурнашы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Куралово авылы җирлеге Рус Бурнашы авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 2023 елның 24 октябрендә 11 сәгатькә билгеләнгән.

2. Югары Ослан муниципаль районының Куралово авылы җирлеге Рус Бурнашы авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 2023 елның 24 октябрендә 13.00 сәгатькә билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 этап: Рус Бурнашы авылы Зур Урам, Чәчәк урамы, Кече урам авылы халкы

2 этап: Рус Бурнашы авылы Совет урамы, Ерак урам, Заречная урамы халкы

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге Рус Бурнашы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Рус Бурнашы авылындагы юлларга чокырлы ремонт өчен, тәэмин итүче хисабына товарны билгеләнгән пунктка илтеп җиткерү.

«ӘЙЕ»　　　　　　　　　　«ЮК».

5. Халык җыеннары үткәрергә:

1 этап: Рус Бурнашы, Зур урамы, 4 нче йорт янында

2 этап: Рус Бурнашы авылы, Заречная урамы, 1 нче йорт янында

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге башлыгы Р.Е.Тарасов